РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТА РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** Буа шәһәре **КАРАР**

05.05.2026 №3-11

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турында нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2016 елның 26 октябрендәге 7-11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы, «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон (15.12.2025 редакциясендә),2011 елның 01 августындагы 50-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турында нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2016 елның 26 октябрендәге 7 `-11 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 6.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.1 өлеш өстәргә:

«2.1.Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән объектка карата килешү төзү, әгәр килешү төзелгән вакытка мондый объект Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объекты (тарихи һәм мәдәни ядкарь) яисә ачыкланган мәдәни мирас объекты булса, рөхсәт ителми.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ рәсми рәвештә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль район башлыгы,
Совет рәисе Р.Р.Камартдинов